**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«19» февраль 2024 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 19 февралендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы торак пунктында 25.11.2023 ел № 5 гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы торак пунктында 25.11.2023 ел № 6 гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме:
Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда үзара салым тәртибендә 1000 сум күләмендә алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эш исемлеген түбәндәге эш төрләре белән тулыландырырга:

- Зиратларны карап тоту;
- Кече Камышлы торак пункты чикләрендә поселок эчендәге һәм сезонлы юлларны ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 129 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 77 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 67 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 10 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы торак пунктында 25.11.2023 ел № 5 гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы торак пунктында 25.11.2023 ел № 6 гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда үзара салым тәртибендә 1000 сум күләмендә алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эш исемлеген түбәндәге эш төрләре белән тулыландырырга:

- Зиратларны карап тоту;
- Кече Камышлы торак пункты чикләрендә поселок эчендәге һәм сезонлы юлларны ремонтлау.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль

районының Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Б. Храбров

Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы: И.Б. Храбров